**Туган телдә халыкның тарихы да, көнкүреше дә, гомумән, барысы да чагыла**

*Т. Миңнуллин*

## Мин татар баласы

Горурланам татар булуыма,
Ата-бабам биргән телемә.
Рәхмәт,-димен,якын итеп,
Туган итеп белгән илемә...

Бәллүр бишек җырларында,
Назын биргән әни сүзләре.
Табигатьнең барча гүзәллеген,
Телем аша,күпме күзләдем.

Мәңге сүнмәс иҗат чишмәсенә,
Татар моңы сеңгән, татар хисләре.
Онытылмас гармун телләрендә,
Дәртләндергән авыл кичләре.

***Солтанова Гөлшат,***

***Мөслим гимназиясенең китапханәчесе***

**Май чабу**

Авызларда эреп китә,
Коймаклар, тәбикмәкләр.
Табыннар сыгылып тора,
Мулдан тәмле күзикмәкләр.

Ничек тәмле булмасын ди,
Ул бит таба икмәге.
Кояш кебек кайнар үзе,
Ул бүген - баш көндә иң кирәге.

***Солтанова Алия,***

***Мөслим гимназиясенең 11 нче сыйныф укучысы***